КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 929

Муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүне, балаларны карау һәм тәрбияләү, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту өчен шартлар тудыруны оештырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне

тәэмин итүне, балаларны карау һәм тәрбияләү, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту өчен шартлар тудыруны оештырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карар 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына) бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин